КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 826

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 1 декабрь, 1161 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республи-касында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 01 декабрь, 1161 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «финанс белән тәэмин итү» сүзләрен «финанс белән тәэмин итү (каплау)» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «финанс белән тәэмин итү» сүзләрен «финанс белән тәэмин итү (каплау)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Юридик затларның Татарстан Республи-касында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба - Тәртип) яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 26 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Тәртипнең 6 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин